**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА СУМАРОКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КЫРЫК ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Яңа Сумароково авылы 20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә**
**муниципаль районы «Яңа Сумароково авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар**
**(иҗтимагый фикер алышулар)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»**
**Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның**
**14 февралендәге Яңа Сумароково авыл җирлеге**
**Советының XXXX сессиясенең**
**№3 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп

## Яңа Сумароково җирлеге Советы

## КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Яңа Сумароково авыл җирлеге Советының XXXX сессиясенең №3 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 4 бүлектә:

*- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:*

«4. Халык алдында тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районының Яңа Сумароково авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы («Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча үткәрелә.

Яңа Сумароково авыл җирлеге советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Яңа Сумароково авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелүчесе («Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) – «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Яңа Сумароково авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **С.Л.Минханова**